ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.11.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3003**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларын гамәлдән чыгару турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 1994 елның 21 декабрендәге «Янгын куркынычсызлыгы турында» 69-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

1.1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү турында» 2017 елның 5 августындагы 2125 номерлы;

1.2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнарның янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүдә, шул исәптән Зеленодольск муниципаль районы территориясендә ирекле янгын күзәтчелеге эшчәнлегендә катнашу формаларын билгеләү турында » 2017 елның 5 августындагы 2126 номерлы;

1.3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының « Зеленодольск муниципаль районы территориясендә янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә халыкны әзерләү тәртибе турында» 2017 елның 5 августындагы 2127 номерлы.

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының

мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин